**СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422723, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с.Алан-Бексер, ул. Центральная, д.19

422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19 йорт

тел./факс +7(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**05 май 2018 ел** **№ 125**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 2016 елның 7 декабрендә кабул ителгән 66 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге муниципаль милкендә булган мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законы, «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 2016 елның 7 декабрендә кабул ителгән 66 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге муниципаль милкендә булган мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, шулай ук Күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрын алып бару, һәм 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законда каралган Күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында булган мәгълүмәтләр буенча белешмәләр бирү нигезендә, күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алу, мондый исәпкә алынырга тиешле күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастр исәбен алып бару турында";

1.2. 12 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Аренда шартнамәләрен, түләүсез файдалану шартнамәләрен, мөлкәт белән ышанычлы идарә шартнамәләрен, хуҗалык алып бару яки оператив идарә итү хокукында беркетелмәгән муниципаль милекне ияләү һәм (яки) файдалану хокукын

күздә тотучы башка шартнамәләрне төзү «Көндәшлекне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында" Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы З.Р.Гарифуллина